**СОВЕТ**
**НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ**
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**СОВЕТЫ**

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы,
Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

---

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**15.06.2020** **№ 150**

**Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советына депутатлар сайлаулары билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Уставының 13 статьясы нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча "Арча хәбәрләре" ("Арский вестник") район газетасында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда ТР, Арча районы, Яңа Кенәр авылы, Совет урамы, 10 йорт; ТР, Арча районы, Сөрде авылы, Совет урамы, 48 йорт; ТР, Арча районы, Шурабаш авылы, Гагарин урамы, 17А йорты адреслары буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Фәхретдинов

СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ